**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ ДӨРЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«13» октябрь, 2024ел Иске Дөреш авылы № 22

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Октябрь-Бүләк авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында «нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 31 октябрендәге 8/1 номерлы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Советы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2024 елның 25 октябренә 11:00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Октябрь-Бүләк авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2025 елда яшәү урыны буенча Иске Дөреш авыл җирлеге Октябрь-Бүләк авылы территориясендә теркәлгән һәр бәлигъ булган кешегә 600 (алты йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- **урам яктырту эшләрен башкару (урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу).**

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Октябрь-Бүләк авылы, М.Җәлил урамы, 28А.

4. РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү, контракт буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, Иске Дөреш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә.

5. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

8. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Иске Дөреш авыл җирлеге Башлыгы Р.М. Дусадбеков

Республика Татарстан Тукай муниципаль районының «Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге ОГРН 1021601376026 р 05-11794/09 Совет Стародрюшского сельского поселения ИНН 1639009739